Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Яңа Чыршылы торак пунктында гражданнар җыены
КАРАРЫ

2024 елның 23 ноябре № 3

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Яңа Чыршылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, 2024 елның 23 ноябрендә узган «Сез Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Яңа Чыршылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Яңа Чыршылы т. п. территориясендә үлән чабу; Яңа Чыршылы т. п. Үзәк урамындагы карт агачларны кисү);
2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яңа Чыршылы торак пунктында Урман урамы буенча грунт-вак таш юлларны ремонтлау; Яңа Чыршылы торак пунктында Заречная ур. буенча чокырларны ремонтлау (асфальт); Яңа Чыршылы торак пунктында Заречная урамы, Үзәк урам, Урман урамы буенча юлларны кардан чистарту

соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 292 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 150 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 150 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Яңа Чыршылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Яңа Чыршылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Сез Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Яңа Чыршылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Яңа Чыршылы т. п. территориясендә үлән чабу; Яңа Чыршылы т. п. Үзәк урамындагы карт агачларны кисү);

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яңа Чыршылы торак пунктында Урман урамы буенча грунт-вак таш юлларны ремонтлау; Яңа Чыршылы торак пунктында Заречная ур. буенча чокырларны ремонтлау (асфальт); Яңа Чыршылы торак пунктында Заречная урамы, Үзәк урам, Урман урамы буенча юлларны кардан чистарту

соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң ун көн эчендә түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Яңа Чыршылы поселогы үзидарә администрациясе бинасында Заречная ур., 25, авыл мәдәният йорты бинасында Үзәк урам 12А йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районының
Яңа Чыршылы авыл җирлеге башлыгы Р.Ә.Мөхәмәтшина